РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 29 октябре Кукмара ш. № 85

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Җир кодексының 72 статьясындагы 1 пункты һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәне расларга (алга таба – Нигезләмә).

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Кукмара муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турында» Кукмара район Советының 2007 елның 16 ноябрендәге 65 номерлы карары;
- «Кукмара муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»Кукмара район Советының 2009 елның 25 декабрендәге 59 номерлы карары;
- «Кукмара муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» Кукмара район Советының 2010 елның 6 августындагы 40 номерлы карары;
- «Кукмара муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Кукмара муниципаль район Советының 2012 елның 23 ноябрендәге 167 номерлы карары;
- «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Кукмара муниципаль районы Советының 2017 елның 20 гыйнварындагы 79 номерлы карары;

- Кукмара район Советының 2007 елның 16 ноябрендәге 65 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Кукмара муниципаль районы Советының 2017 елның 20 октябрендәге 121 номерлы карары

3. Әлеге карар, Нигезләмәнең 5.2 пунктыннан, Нигезләмәнең 6 бүлегеннән һәм 3 нче кушымтасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән, әмма 2022 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел, үз көченә керә.

Нигезләмәнең 5.2 пункты 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Нигезләмәнең 6 бүлеге һәм Нигезләмәгә 3 нче кушымта 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 29 октябрендәге 85 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар (алга таба – контроль үткәрелә торган затлар) тарафыннан җир мөнәсәбәтләре объектларына карата аларны бозган өчен законнарда административ җаваплылык каралган җир законнары таләпләренең мәҗбүри үтәлешен муниципаль тикшерүне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели (алга таба – муниципаль җир контроле).

1.2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә (алга таба – район) муниципаль җир контроле предметы булып түбәндәгеләр тора:

1) контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан Россия Федерациясе законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка хокукый актларында билгеләнгән, җирләрдән файдалану өлкәсендә аларны бозган өчен Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары белән административ җаваплылык каралган мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәү.

2) рөхсәт бирү документларындагы таләпләрне үтәү (тормышка ашыру);

3) Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәлергә тиешле документлар таләпләрен үтәү;

4) контроль чаралары нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларның үтәлеше.

1.3. Районда җир мөнәсәбәтләре объектларына карата муниципаль җир контроле Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба – Контроль органы) тарафыннан башкарыла.

Контроль органы исеменнән муниципаль җир контролен түбәндәге вазыйфаи затлар (алга таба – вәкаләтле вазыйфаи затлар) гамәлгә ашыра:

1) Контроль органы җитәкчесе (җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы зат);

2) Контроль органының вазыйфаи вазыйфаларына вазыйфаи регламент яисә вазыйфаи инструкция нигезендә муниципаль җир контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру керә торган вазыйфаи заты.

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда, вәкаләтле вазыйфаи затлар хокукларга, бурычларга ия һәм 248-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә җаваплылык тоталар.

1.4. Контроль органы түбәндәгеләрне үтәү буенча муниципаль җир контролен гамәлгә ашыра:

- түбәндәгеләрне булдырмау турында җир законнары таләпләре:

а) җир кишәрлекләрен үз белдегең белән алу яки җир кишәрлегеннән законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән җиргә хокук билгели торган документлардан башка, ә кирәк булган очракта – хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруны рөхсәт итүче документлардан башка файдалану;

б) җирдән файдалану хокукын үз белдеге белән бирү;

в) җир кишәрлекләрен үз белдеге белән алмаштыру;

- юридик затлар тарафыннан җир кишәрлекләреннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын җир кишәрлекләрен арендалау хокукына яңадан рәсмиләштерү яисә җир кишәрлекләрен милеккә алу турындагы таләпләр;

- җир кишәрлекләрен максатчан билгеләнеше буенча файдалану турында җир законнары таләпләре;

- авыл хуҗалыгы җитештерүе, торак һәм башка төзелеш өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән мәҗбүри рәвештә күрсәтелгән максатларда файдалану турында җир законнары таләпләре (әйләнеше «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдәнбулган җир кишәрлекләреннән мәҗбүри авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару яисә авыл хуҗалыгы җитештерүе белән бәйле башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдалануга бәйле таләпләрне үтәүдән тыш);

- җир биләүчеләр, җирдән файдаланучылар һәм җирләрне арендалаучылар тарафыннан граждан һәм җир законнары белән билгеләнгән җир кишәрлекләрен үзләштерү сроклары;

- җир кишәрлекләрен арендалаучылар тарафыннан җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсе шартлары;

- җирләрне вакытында кайтару;

- җирләрнең торышы һәм алардан файдалану турында дөрес белешмәләр бирү;

- җирләрдән файдалану мәсьәләләре буенча законнарның башка таләпләрен үтәү.

1.5. Муниципаль җир контроле объектлары (алга таба – контроль объектлары) булып түбәндәгеләр тора:

гражданнар һәм алар кысаларында мәҗбүри таләпләр, шул исәптән эшчәнлек, гамәлләр (гамәл кылмау) алып баручы гражданнарга һәм оешмаларга карата куела торган таләпләр үтәлергә тиешле оешмаларның эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмаулары);

- мәҗбүри таләпләр куела торган гражданнар һәм оешмалар эшчәнлеге нәтиҗәләре.

- районның авылара территориясендә урнашкан җир мөнәсәбәтләре объектлары; район составына керүче авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан җир мөнәсәбәтләре объектлары; район составына керүче шәһәр җирлеге чикләрендә урнашкан җир мөнәсәбәтләре объектлары (район һәм шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары арасында төзелгән муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында килешү булганда).

Җир мөнәсәбәтләре объектлары дигәндә Россия Федерациясе Җир кодексының 6 статьясында (алга таба – РФ ҖК) күрсәтелгән объектлар аңлашыла.

1.6. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларының исәбен алуны Контроль органы тәэмин итә.

1.7. Муниципаль җир контроле түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

РФ ҖК;

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы;

248-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Дәүләт җир күзәтчелеген гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органнарының муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органнар белән үзара хезмәттәшлеге Кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 26 декабрендәге 1515 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары;

«Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү Кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары;

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типик формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2021 елның 31 маенда 63710 номеры белән теркәлгән);

Татарстан Республикасы Җир кодексы;

«Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2015 елның 13 октябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;

Район Уставы*;*

«Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасын төзү турында» Кукмара район Советының 2005 елның 22 декабрендәге 28 номерлы карары белән расланган Контроль органы турында Нигезләмә;

Нигезләмә.

1.8. Нигезләмә максатларында төп терминнар һәм төшенчәләр, әгәр Федераль законнарда, Нигезләмәдә башкасы каралмаган яисә Нигезләмә белән җайга салына торган хокук мөнәсәбәтләренең асылыннан килеп чыкмый икән, 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнә торган мәгънәләрдә кулланыла.

## II. Зыян (югалту) китерү куркынычын (риск) кисәтү һәм мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы (риск) индикаторлары

2.1. Муниципаль җир контроле профилактик чараларны һәм контроль чараларны сайлап алуны, аларны эчтәлеген (шул исәптән тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрнең күләме), интенсивлыкны һәм нәтиҗәләрне билгели торган зыян (югалту) китерү куркынычы белән идарә итү нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Зыян (югалту) китерү куркынычы белән идарә итү максатлары өчен муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль объектлары зыян (югалту) китерү куркынычы булган түбәндәге категорияләрнең берсенә керә:

урта куркыныч (средний риск);

уртача куркыныч (умеренный риск);

түбән куркыныч (низкий риск).

2.3. Җир кишәрлекләрен билгеле бер куркыныч категориясенә кертү Контроль органы тарафыннан муниципаль җир контроле уздырганда гражданнар, юридик затлар һәм (яки) шәхси эшмәкәрләр тарафыннан файдаланыла торган җирләрне һәм җир кишәрлекләрен билгеле бер куркыныч категориясенә кертү критерийларына таянып, Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә Контроль органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.4. Җир кишәрлекләрен куркыныч категорияләренә керткәндә, Контроль органы тарафыннан шул исәптән түбәндәгеләр кулланыла:

- Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрындагы мәгълүматлар;

- вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан контроль үткәрелә торган затлар белән үзара бәйләнешсез контроль чаралар үткәргәндә алына торган белешмәләр;

- дәүләт җир күзәтчелеге органнарыннан алынган белешмәләр.

- Контроль органы карамагында булган башка мәгълүматлар.

2.5. Контроль объекты билгеле бер куркыныч категориясенә кертелмәгән очракта, ул түбән куркыныч категориясенә кертелгән дип санала.

2.6. Контроль органы объектның куркынычның бүтән категориясе критерийларына туры килүе турында яисә куркыныч критерийларын үзгәртү турында белешмәләр кергән көннән биш эш көне эчендә контроль объектының куркыныч категориясен үзгәртү турында Карар кабул итә.

2.7. Контроль органы куркыныч категорияләренең берсенә кертелгән җир кишәрлекләре исемлеген алып бара (алга таба – җир кишәрлекләре исемлеге).

Җир кишәрлекләре исемлеге түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) җир кишәрлегенең кадастр номеры яки, ул булмаганда, җир кишәрлегенең урнашу урыны адресы;

б) җир кишәрлеге кертелгән куркыныч категориясе;

в) җир кишәрлеген куркыныч категориясенә кертү турында карар реквизитлары.

2.8. Куркыныч категорияләре күрсәтелгән җир кишәрлекләре исемлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә районның рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлектә урнаштырыла.

2.9. Бирелгән куркыныч категориясеннән чыгып, планлы контроль чараларының түбәндәге төрләре һәм ешлыгы билгеләнә:

урта куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата – 3 елга планлы бер тикшерү чарасы;

уртача куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата – 5 елга планлы бер тикшерү чарасы.

Түбән куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата планлы контроль чаралары үткәрелми.

2.10. Муниципаль җир контроле өчен мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында күрсәтелгән. Күрсәтелгән индикаторлар Контроль органы тарафыннан планнан тыш тикшерү чарасын үткәрү һәм төрен сайлап алу турында карар кабул иткәндә зыян (югалту) китерү куркынычын бәяләү максатларында эшләнгән.

## III. Зыян (югалту) китерү куркынычын кисәтү

3.1. Профилактик чаралар контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намус белән үтәүне стимуллаштыру, мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яки) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерүгә китерә торган шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү һәм мәҗбүри таләпләрне контроль үткәрелә торган затларга җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында мәгълүматлылыкны арттыру максатларында Контроль органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.2. Профилактик чаралар ел саен Контроль органы тарафыннан раслана торган закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычын профилактикалау программасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Шулай ук әлеге программада каралмаган профилактик чаралар үткәрелергә мөмкин.

3.3. Муниципаль җир контролен тормышка ашырганда, профилактик чараларның түбәндәге төрләре үткәрелә:

мәгълүмат җиткерү;

кисәтү белдерү;

консультация бирү;

профилак визит.

3.4. Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Контроль органы тарафыннан тиешле белешмәләрне рәсми сайттагы контроль

эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә, массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру юлы белән, контроль үткәрелә торган затларның дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетлары аша (алар булганда) һәм башка рәвешләрдә башкарыла.

Контроль органы рәсми сайтның контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлегендә 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлешендә каралган мәгълүматларны урнаштырырга һәм актуаль хәлдә тотарга тиеш.

3.5. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү (алга таба – кисәтү) Контроль органында әзерләнә торган мәҗбүри таләпләрне бозу яисә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр булган очракта, һәм (яисә) мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китергәне яки закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычы тудырганы турында расланган мәгълүматлар булмаганда, контроль үткәрелә торган затка игълан ителә.

Кисәтү, югарыда күрсәтелгән белешмәләр алынганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, Контроль органы җитәкчесе (җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы) тарафыннан игълан ителә.

3.6. Кисәтүдә тиешле мәҗбүри таләпләргә, аларны күздә тоткан норматив хокукый актка, контроль үткәрелә торган затның нинди конкрет гамәлләре (гамәл кылмавы) мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә яки китерергә мөмкин булуы турында мәгълүматка күрсәтмә, шулай ук әлеге таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрү турында тәкъдим булырга тиеш һәм контроль үткәрелә торган зат тарафыннан мәгълүмат һәм документлар тапшыруны таләп итү була алмый.

Кисәтү язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә рәсмиләштерелә, теркәү номеры биреп, кисәтүләрне исәпкә алу журналында теркәлә һәм контроль үткәрелә торган зат адресына җибәрелә.

3.7. контроль үткәрелә торган зат, кисәтү алган көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, кисәтүгә карата каршылык (возражение) бирергә хокуклы.

Каршылыкта түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең, гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

2) салым түләүченең – юридик затның, шәхси эшмәкәрнең идентификация номеры;

3) паспортның яки шәхесне раслаучы башка документның сериясе һәм номеры, яшәү урыны, элемтә өчен телефон (гражданнар өчен);

4) контроль үткәрелә торган зат адресына җибәрелгән кисәтү датасы һәм номеры;

5) контроль үткәрелә торган затның кисәтүдә күрсәтелгән мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә яисә китерә ала торган гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата позицияне нигезләү.

Контроль органга карата каршылыклар 248-ФЗ номерлы федераль закон белән билгеләнгән очракларда контроль үткәрелә торган зат тарафыннан кәгазьдә почта аша яки гади электрон имза яки көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә Контроль органының кисәтүдә күрсәтелгән электрон почта адресына яисә кисәтүдә күрсәтелгән башка ысуллар белән җибәрелә.

Контроль органы каршылыкларны карый, каршылыклар алган көннән алып 20 эш көне эчендә, контроль үткәрелә торган затка карау нәтиҗәләре буенча килешү турында җавап яки каршылык белән нигезле килешмәү җибәрә.

Каршылыкта тәкъдим ителгән дәлилләрне кабул иткән очракта, Контроль органы җитәкчесе (җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы зат) кисәтүне юкка чыгара, игълан ителгән кисәтүләр журналында бу хакта тамга куела.

Каршылык белән килешмәү турындагы мәгълүмат, тиешле нигезләмәләр күрсәтелеп, яисә кисәтүне юкка чыгару турында мәгълүмат контроль үткәрелә торган зат адресына язмача яки электрон документ формасында җибәрелә.

Каршылыкларны карау нәтиҗәләре мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чараларны оештыру һәм уздыру, муниципаль җир контролен оештырганда куркыныч-юнәлешле алым (риск-ориентированный подход) куллануны камилләштерү максатларында һәм гражданнарның, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын һәм ирекләрен чикләүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен Контроль органы тарафыннан кулланыла.

3.8. контроль үткәрелә торган затларның һәм аларның вәкилләренең мөрәҗәгатьләре буенча муниципаль җир контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләргә карата консультация Контроль органының вазыйфаи затлары тарафыннан телдән телефон аша да, видео-конференц-элемтә аша да, шәхси кабул иткәндә дә, профилактик чара, контроль чара уздыру барышында да, шулай ук язмача да бирелә.

Шәхси кабул итү Контроль органы җитәкчесе (җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы) тарафыннан үткәрелә. Кабул итү урыны, шулай ук кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат рәсми сайтта урнаштырыла.

Контроль органы консультацияләрне исәпкә алу журналы алып бара.

3.9. Консультация телдән яки язма формада түбәндәге мәсьәләләр буенча башкарыла:

а) муниципаль җир контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру;

б) Нигезләмәдә билгеләнгән контроль чараларны гамәлгә ашыру тәртибе;

в) Контроль органы карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тәртибе;

г) үтәлешләрен бәяләү Контроль органы тарафыннан контроль чаралар кысаларында гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган

норматив хокукый актлар (аларның аерым нигезләмәләре) турында мәгълүмат алу;

3.10. Язма рәвештә консультация бирү Контроль органының вазыйфаи заты тарафыннан түбәндәге очракларда башкарыла:

а) контроль үткәрелә торган зат тарафыннан консультация мәсьәләләре буенча язмача җавап бирү турында язмача сорату бирлегән;

б) куелган сорауларга консультацияләр бирү вакытында җавап бирү мөмкин түгел;

в) куелган сорауларга җавап бирү өстәмә мәгълүмат соратып алуны таләп итә.

3.11. Контроль органы контроль үткәрелә торган затларга һәм аларның вәкилләренә телдән консультация бирү мәсьәләләре буенча язма рәвештә мәгълүмат бирми.

контроль үткәрелә торган зат «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән срокларда язмача җавап бирү турында запрос җибәрергә хокуклы.

3.12. Консультация биргәндә Контроль органының вазыйфаи заты Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга тиеш.

Консультация бирү барышында түбәндәгеләр бирелә алмый:

Контроль органы вазыйфаи затларының, контроль чарада катнашучыларның конкрет чарасына, карарларына һәм (яки) гамәлләренә бәя биргән мәгълүмат;

контроль чара кысаларында үткәрелгән экспертиза, сынаулар нәтиҗәләре.

Консультация барышында Контроль органының вазыйфаи затына билгеле булган мәгълүмат аның тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча контроль үткәрелә торган затны бәяләү максатларында кулланыла алмый.

3.13. Контроль үткәрелә торган затлардан һәм аларның вәкилләреннән Контроль органына бер типтагы 5 һәм аннан күбрәк мөрәҗәгать кергән очракта, консультация рәсми сайттагы контроль эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә Контроль органының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган язма аңлатма урнаштыру юлы белән бирелә.

3.14. Профилактик визит контроль үткәрелә торган затның эшчәнлек алып бару урынында профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видео-конференц-элемтәдән файдалану юлы белән үткәрелә.

Профилактик визит барышында контроль үткәрелә торган затка үз эшчәнлегенә йә үз карамагындагы контроль объектларына карата куела торган мәҗбүри таләпләр, аларның куркыныч критерийларына туры килүе, нигезләүләр һәм куркыныч категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары турында, шулай ук аларны тиешле куркыныч категориясенә кертүдән чыгып, контроль объектына карата үткәрелә торган контроль чараларның төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында мәгълүмат бирелә.

Профилактик визит үткәргәндә контроль объектларының закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерүгә турыдан-туры куркыныч тудыруы яки мондый зыян (югалту) китерелүе ачыкланган очракта, Контроль органының вазыйфаи заты бу хакта кичекмәстән Контроль органы җитәкчесенә, контроль чаралар үткәрү турында карар кабул итү өчен, үткәрелгән профилактик визит турында хисап рәвешендә мәгълүмат җибәрә.

3.15. Мәҗбүри профилактик визит җир законнарының мәҗбүри таләпләрен үтәү белән бәйле эшчәнлекне тормышка ашыруга керешүче контроль үткәрелә торган затларга карата, мондый эшчәнлек башланганнан бирле, бер ел дәвамында үткәрелә.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында контроль үткәрелә торган затка аны үткәрү датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында хәбәрнамә язма рәвештә яисә электрон документ формасында төзелә һәм түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

1) хәбәрнамәне төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) Контроль органы исеме;

3) контроль үткәрелә торган затның тулы исеме;

4) вәкаләтле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

5) мәҗбүри профилактик визитның датасы, вакыты һәм урыны;

6) вәкаләтле вазыйфаи зат имзасы.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында хәбәрнамә контроль үткәрелә торган зат адресына язмача яки электрон документ формасында җибәрелә.

Контроль үткәрелә торган зат, бу хакта Контроль органына аны үткәрү датасына кадәр кимендә өч эш көне алдан хәбәр итеп, мәҗбүри профилактик визит уздырудан баш тартырга хокуклы.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү вакыты Контроль органы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә һәм бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

## IV. Контроль чаралар

4.1. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда Контроль органы тарафыннан күрсәтелгән чаралар кысаларында түбәндәге контроль чаралар һәм контроль гамәлләр үткәрелергә мөмкин:

а) инспекция визиты (карау, сораштыру, мәҗбүри таләпләр нигезендә контроль үткәрелә торган зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) яисә контроль объекты урнашкан (эшчәнлек алып бара торган) урында булырга тиеш булган документларны таләп итү, язма аңлатмалар алу, инструменталь тикшереп чыгу (обследование) юлы белән;

а) рейд тикшерүе (карау, сораштыру, язма аңлатма алу, мәҗбүри таләпләр нигезендә контроль үткәрелә торган зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) яисә контроль объекты урнашкан (эшчәнлек алып бара торган) урында булырга тиеш булган

документларны таләп итү, инструменталь тикшереп чыгу, экспертиза юлы белән;

в) документар тикшерү (язмача аңлатмалар алу, документлар таләп итү, экспертизалар үткәрү юлы белән);

г) күчмә тикшерү (тикшерү, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документлар таләп итү, инструменталь тикшереп чыгу юлы белән);

д) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (җирләр, җир кишәрлекләре һәм аларның өлешләре турында булган мәгълүматларны, шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында керә, муниципаль хезмәтләр һәм функцияләрне башкару кысаларында бирелә торган белешмәләрне, шулай ук дәүләт, муниципаль һәм ведомство мәгълүмат системаларында булган белешмәләрне анализлау юлы белән);

е) күчмә тикшереп чыгу (карау, инструменталь тикшереп чыгу юлы белән (видеоязма кулланып)).

4.2. Контроль чаралар барышында түбәндәге контроль гамәлләр башкарыла:

а) карау;

б) сораштыру;

в) язмача аңлатмалар алу;

г) документлар таләп итү;

д) инструменталь тикшереп чыгу;

е) экспертиза.

Контроль гамәлләр үткәрү тәртибе 248-ФЗ номерлы Федераль законның 14 бүлеге белән җайга салына.

4.3. Контроль үткәрелә торган зат белән үзара хезмәттәшлек түбәндәге контроль чараларны үткәргәндә гамәлгә ашырыла:

а) инспекция визиты;

б) рейд тикшерүе;

в) документлар буенча (документарная) тикшерү;

г) күчмә (урынга барып) тикшерү.

4.4. Контроль үткәрелә торган зат белән үзара бәйләнешсез рәвештә түбәндәге контроль чаралар үткәрелә:

а) контроль таләпләрнең үтәлешен күзәтү;

б) күчмә тикшереп чыгу (обследование).

4.5. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында түбәндәге планлы тикшерү чаралары үткәрелергә мөмкин:

а) инспекция визиты;

б) рейд тикшерүе;

в) документлар буенча (документарная) тикшерү;

г) күчмә (урынга барып) тикшерү.

4.6. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында түбәндәге планнан тыш тикшерү чаралары үткәрелергә мөмкин:

а) инспекция визиты;

б) рейд тикшерүе;

в) документлар буенча (документарная) тикшерү;

г) күчмә (урынга барып) тикшерү.

д) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү;

е) күчмә тикшереп чыгу (обследование).

4.7. Контроль чаралар үткәрү нигезләре 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнә.

4.8. Вәкаләтле вазыйфаи затлар биремнәре нигезендә, Контроль органының эш планнарында булган биремнәрне дә кертеп, вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан үзара бәйләнешсез контроль чаралар, шул исәптән, шул исәптән 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән очракларда үткәрелә.

4.9. контроль үткәрелә торган зат яисә аның вәкиле барында үткәрелергә тиешле контроль чараларны үткәргәндә һәм контроль гамәлләр кылганда, контроль үткәрелә торган зат белән үзара бәйләнешне таләп итми торган тикшерү чараларын үткәрүдән, контроль гамәлләр кылудан тыш, контроль үткәрелә торган затның яисә аның вәкиленең булуы мәҗбүри.

Контроль үткәрелә торган зат яисә аның вәкиле булмаган, кконтроль үткәрелә торган зат тарафыннан Контроль органына аның контроль чараны үткәргәндә катнашу мөмкинлеге булмавы турында мәгълүмат бирү очракларында, әгәр контроль чараны үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләү контроль үткәрелә торган зат булмаса да үткәрелергә мөмкин, ә контроль үткәрелә торган затка контроль чара үткәрү турында тиешенчә хәбәр ителгән икән, контроль гамәлләр башкарыла.

4.10. Контроль үткәрелә торган затлар булган шәхси эшмәкәр, гражданин Контроль органына түбәндәге очракларда контроль чара үткәргәндә булу мөмкинлеге булмавы турында мәгълүмат бирергә хокуклы:

1) контроль чара үткәрү вакытында медицина учреждениесендә стационар дәвалауда булу;

2) контроль чара үткәрү вакытына вакытлыча эшкә сәләтсезлек.

3) Россия Федерациясеннән читтә булу;

3) административ арест рәвешендә административ җәза билгеләү;

4) җинаять кылуда шикләнелүче физик затка карата читкә чыгып китмәү һәм үз-үзеңне тоту турында язылу, билгеле бер гамәлләрне тыю, сак астына алу, йорт аресты рәвешендә кисәтү чарасын сайлау;

контроль чара үткәргәндә затның катнашуына каршы килә торган җиңеп чыга алмастай көч барлыкка килү (ххәрби хәрәкәтләр, катастрофа, табигый бәла-каза, зур авария, эпидемия һәм башка гадәттән тыш хәлләр).

Контроль чараны үткәргәндә катнашу мөмкинлеге булмау турында мәгълүмат килеп ирешкәндә, аны үткәрү Контроль органы тарафыннан шәхси эшмәкәр, гражданинның әлеге мөрәҗәгатенә сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытка күчерелә.

4.11. Җиңеп булмастай көч шартлары килеп туган очракта, контроль үткәрелә торган зат Контроль органы адресына түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиешле мәгълүмат җибәрә:

а) җиңеп булмастай көч шартларын һәм аларның дәвамлылыгын тасвирлау;

б) барлыкка килгән җиңеп булмастай көчнең барлыкка килгән шартлары һәм контроль чарасын уздырганда катнашу мөмкин булмау яисә тоткарлану арасындагы сәбәп-нәтиҗә элемтәсе турында белешмәләр;

в) контроль чарасын уздырганда катнашуга комачаулаучы хәлләрне бетерү өчен кирәкле срокка күрсәтмә.

4.12. Муниципаль җир контролен оештырганда һәм гамәлгә ашырганда, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, шул исәптән электрон формада Контроль органы түләүсез нигездә бүтән органнардан яки күрсәтелгән органнарга караган оешмалардан алар карамагында булган документларны һәм (яки) белешмәләрне ала. Күрсәтелгән документлар һәм (яки) белешмәләр исемлеге, аларны бирү тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

4.13. Планлы контроль чаралар чираттагы календарь елына планлы контроль чаралар үткәрүнең Контроль органы тарафыннан төзелә һәм прокуратура органы белән килештерелергә тиешле планы (алга таба – еллык контроль чаралар планы) нигезендә үткәрелә.

Контроль чараларның еллык планын формалаштыру, аны прокуратура органнары белән килештерү, ел дәвамында контроль чараларны аңа кертү һәм аннан төшереп калдыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

4.14. Вәкаләтле вазыйфаи затлар һәм контроль гамәлләр кылуга җәлеп ителә торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу дәлилләрен теркәү өчен, вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелә торган фотога төшерү һәм/яки аудио һәм видеоязма, геодезик һәм картометрик үлчәмнәр кулланылырга мөмкин.

Фотога төшерүне, аудио- һәм видеоязмаларны, тикшерү чараларын башкарганда мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәүнең башка алымнарын куллану зарурлыгы турындагы карар вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан мөстәкыйль кабул ителә.

Фотога төшерү, аудио- һәм видеоязмалар контроль үткәрелә торган затка мәҗбүри хәбәр итеп башкарыла.

4.15. Фотога төшерү ярдәмендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны теркәү кимендә ике фотосурәт ясап башкарыла. Фотога төшерү нокталары һәм юнәлешләре контроль чара үткәрелә торган җир мөнәсәбәтләре объекты схемасында билгеләнә. Тикшерү чараларын үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне үтәү (бозу) дәлилләрен теркәү өчен кулланыла торган фотога төшерү һәм видеоязма җитәрлек яктыртылган шартларда башкарылырга тиеш.

Аудио - һәм видеоязма тикшерү чарасы барышында өзлексез, яздыру башында һәм ахырында язылу башлануның һәм тәмамлануның датасы, урыны, вакыты турында хәбәрнамә белән башкарыла. Яздыру барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуның урыны һәм характеры җентекләп теркәлә һәм күрсәтелә.

4.16. Фотога төшерү, аудио һәм видеоязмалар, геодезик һәм картометрик үлчәүләр һәм бу максатлар өчен кулланылган техник чаралар турындагы мәгълүмат контроль чара нәтиҗәләре буенча төзелә торган актта һәм

контроль чара кысаларында үткәрелә торган контроль гамәл нәтиҗәләре буенча төзелә торган беркетмәдә чагыла.

Фотога төшерү һәм видеоязмаларны мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү өчен куллану дәүләт серен саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма үткәрү нәтиҗәләре контроль чарасы актына кушымта булып тора.

Контроль чаралары уздыру барышында инструменталь тикшереп чыгу Контроль органының вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла торган геодезик үлчәүләр (билгеләмәләр) һәм (яки) картографик үлчәүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.17. Инспекция визиты конкрет контроль үткәрелә торган зат һәм (яки) хуҗасы (кулланучы) белән үзара бәйләнештә контроль үткәрелә торган зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) яисә контроль объекты урнашкан (эшчәнлек алып бара торган) урында алып барыла.

Инспекция визиты контроль үткәрелүче затка һәм контроль объектының милекчесенә алдан хәбәр итмичә үткәрелә.

Бер эшчәнлек урынында яки бер контроль объектында инспекция визитын үткәрү бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

Контроль үткәрелә торган затлар яки аларның вәкилләре Контроль органының вазыйфаи затының биналарга, корылмаларга, помещениеләргә тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

4.18. Рейд тикшерүе контроль объектына ия булу, аннан файдалану яки идарә итү белән шөгыльләнүче теләсә нинди контроль үткәрелә торган затларга карата, алар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү максатларында үткәрелә.

Рейд тикшерүе чарасын үткәрү тикшерү чараларын үткәрү турындагы карар нигезендә, тикшерү чарасын үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертлар, белгечләр катнашында (кирәк булганда), уртак (ведомствоара) контроль чарасы формасында (кирәк булганда) тормышка ашырыла.

Рейд тикшерүен үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артырга тиеш түгел. Рейд тикшерүе вакытында бер контроль үткәрелә торган зат белән үзара хезмәттәшлек итү срогы бер эш көненнән дә арта алмый.

Рейд тикшерүе үткәргәндә, Контроль органның вазыйфаи затлары контроль объектында булган затлар белән хезмәттәшлек итәргә хокуклы.

Контроль үткәрелә торган затлар рейд тикшерүе барышында вәкаләтле вазыйфаи затларның контроль объектларына тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

Рейд тикшерүе барышында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, вәкаләтле вазыйфаи зат хокук бозуга юл куйган һәр контроль үткәрелә торган затка карата урында акт төзи, шул ук вакытта контрольнең барлык нәтиҗәләренә карата мәгълүматны үз эченә алган аерым акт рәсмиләштерелми.

4.19. Документар тикшерү Контроль органының урнашкан урынында үткәрелә, аның предметы булып бары тик контроль үткәрелә торган затларның оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгели торган документларындагы белешмәләр, шулай ук шулай ук аларның эшчәнлеген тормышка ашырганда кулланыла торган һәм мәҗбүри таләпләрне һәм Контроль органының карарларын үтәү белән бәйле һәм контроль үткәрелә торган зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) урнашкан (эшчәнлек алып бара торган) урында булган документлар гына тора.

Документар тикшерү барышында контроль үткәрелә торган затларның Контроль органы карамагында булган документлары, алдагы тикшерү чаралары нәтиҗәләре, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау материаллары һәм муниципаль җир контроленең әлеге контроль үткәрелә торган затларына карата башкарылган эш нәтиҗәләре турында башка документлар карала.

Контроль органы карамагында булган документлардагы белешмәләрнең дөреслеге нигезле шик тудыра яки бу белешмәләр контроль үткәрелә торган затның мәҗбүри таләпләрне үтәвен бәяләргә мөмкинлек бирми икән, Контроль органы контроль үткәрелә торган зат адресына документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбен җибәрә.

Контроль үткәрелә торган зат зат күрсәтелгән документларны таләп алынганнан соң ун эш көне эчендә Контроль органына тапшырырга тиеш.

4.20. Әгәр дә документар тикшерү барышында контроль үткәрелә торган зат биргән документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыкланган булса, яисә әлеге документлардагы мәгълүматларның контроль органында булган документлардагы белешмәләргә һәм (яки) муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве ачыкланса, хаталар, каршылыклар һәм мәгълүматларның туры килмәве турында контроль үткәрелә торган затка ун эш көне эчендә кирәкле аңлатмаларны тапшыру таләбе белән мәгълүмат җибәрелә.

Контроль үткәрелә торган зат, таләп ителә торган аңлатмалардан тыш, элек бирелгән документларның дөреслеген раслаучы документларны Контроль органына өстәмә рәвештә тапшырырга хокуклы.

Документар тикшерү уздырганда, документар тикшерү предметына карамый торган белешмәләр һәм документлар, шулай ук Контроль органы тарафыннан башка органнардан алынырга мөмкин булган контроль үткәрелә торган затның белешмәләре һәм документлары таләп ителми.

4.21. Документар тикшерү үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артырга тиеш түгел.

Күрсәтелгән срокка Контроль органы тарафыннан контроль үткәрелә торган затка документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны тапшырырга таләп җибәрелгән мизгелдән таләптә күрсәтелгән документларны Контроль органына тапшырганчыга кадәрге чор, шулай ук контроль үткәрелә торган затка Контроль органы контроль

үткәрелә торган зат биргән документларда хаталар һәм (яки) каршылыкларны ачыклау турында яисә әлеге документлардагы мәгълүматларның контроль органында булган документлардагы белешмәләргә һәм (яки) муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында мәгълүмат җибәргәннән соңгы чор, һәм кирәкле аңлатмаларны язмача бирергә таләпләр җибәргәннән күрсәтелгән аңлатмаларны контроль органга тапшырганчыга кадәрге чор кертелми.

4.22. Планнан тыш документар тикшерү прокуратура органнары белән килешмичә генә үткәрелә.

4.23. Күчмә тикшерү контроль объектлары булган һәм (яки) алардан файдаланучы конкрет контроль үткәрелә торган зат хезмәттәшлек итү юлы белән, мондый зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү, шулай ук Контроль органы карарларының үтәлешен бәяләү максатларында үткәрелә.

Күчмә тикшерү контроль үткәрелә торган зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) яисә контроль объекты урнашкан (эшчәнлек алып бара торган) урында алып барыла.

4.24. Күчмә тикшерү 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда үткәрелә.

4.25. Планнан тыш күчмә тикшерү, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясындагы 5 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, бары тик прокуратура органнары белән килешенеп кенә үткәрелергә мөмкин.

Күчмә тикшерү үткәрү турында контроль үткәрелә торган затка күчмә тикшерүне үткәрү турында карарның күчермәсен, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында каралган тәртиптә, ул башланганчы егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча, җибәрү юлы белән хәбәр ителә.

4.26. Күчмә тикшерү үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артырга тиеш түгел.

Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата күчмә тикшерү уздыру барышында хезмәттәшлекнең гомуми вакыты кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән арта алмый.

Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Оешмага карата күчмә тикшерүне үткәрү вакыты әлеге пунктта күрсәтелгән сроклар чикләрендә һәр филиал, вәкиллек, оешманың аерымланган структур бүлекчәсе яисә җитештерү объекты буенча аерым билгеләнә.

4.27. Күчмә тикшереп чыгу контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен бәяләү максатларында үткәрелә.

Күчмә тикшереп чыгу оешманың (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) яисә контроль объекты урнашкан (эшчәнлек алып бара торган) урында, гражданинның эшчәнлек алып бару урынында, контроль үткәрелә торган объектының урнашу урыны буенча үткәрелергә мөмкин, шул ук вакытта контроль үткәрелә торган зат белән хезмәттәшлек итү рөхсәт ителми.

Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган карарлар кабул ителә алмый.

Бер объектны (бер-берсенә якын урнашкан берничә объектны) күчмә тикшереп чыгу уздыру вакыты бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

4.28. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) контроль органында булган контроль объектлары турында мәгълүматларны, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында керә торган, мәҗбүри таләпләрне үтәү кысаларында контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны, шулай ук дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларындагы мәгълүматларны, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән алынган мәгълүматларны, һәркем өчен ачык булган мәгълүматларны, шулай ук фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган хокук бозуларны теркәүнең автоматик режимында эшләүче техник чараларын кулланып алынган мәгълүматларны җыю, анализлаудан гыйбарәт.

Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәткәндә (куркынычсызлык мониторингы), контроль үткәрелә торган затларга мәҗбүри таләпләрдә билгеләнмәгән бурычлар йөкләнә алмый.

Әгәр мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) барышында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү яисә зыян (югалту) китерү куркынычы барлыкка килү фактлары, мәҗбүри таләпләрнең бозылуы, мәҗбүри таләпләрне бозуның әзерләнүе яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр ачыкланса, Контроль органы тарафыннан 248-ФЗ номерлы Федераль законның 74 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән карарлар кабул ителергә мөмкин.

4.29. Контроль үткәрелә торган зат белән үзара бәйләнешне күздә тота торган контроль чара тәмамланганнан соң, контроль чара акты төзелә (алга таба – акт). Мондый чара үткәрү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланса, актта нәкъ менә нинди мәҗбүри таләп бозылуы, нинди норматив хокукый акт һәм аның структур берәмлеге тарафыннан билгеләнүе күрсәтелә. Ачыкланган бозуларны контроль чара тәмамланганчы бетергән очракта, актта аны бетерү факты күрсәтелә. Мәҗбүри таләпләрне бозуга дәлил булган документлар, башка материаллар актка теркәлергә тиеш. Контроль чараларын үткәргәндә тутырылган тикшерү кәгазьләре актка теркәлә.

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларындагы тикшерү барышында Россия Федерациясе законнары белән административ һәм башка җаваплылык каралган җир законнары таләпләрен бозу ачыкланган очракта, актта ачыкланган бозу билгеләре турында мәгълүмат күрсәтелә. Контроль органы актның күчермәсен дәүләт җир күзәтчелеге органына җибәрә.

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларындагы тикшерү барышында Татарстан Республикасы законнары белән административ җаваплылык каралган җир законнары таләпләрен бозу ачыкланган очракта,

ачыкланган бозулар өчен җаваплылыкка тарту РФ Җир кодексы, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле вазыйфаи затлар контроль чара тәмамланганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, җир кишәрлеге урнашкан урын буенча җирлекнең җирле үзидарә органнарына яки җир кишәрлеге авылара территориядә булган очракта – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет), үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча күрсәтелгән вазыйфаи затлар тарафыннан җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану һәм (яки) җир кишәрлегеннән файдалану чикләүләре нигезендә мондый объектны урнаштыру рөхсәт ителми торган җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектын урнаштыру факты ачыкланган очракта, әлеге фактны раслаучы документларны кушып, үз белдекләре белән төзелгән төзелеш объекты ачыклануы турында хәбәрнамә җибәрәләр.

Актны рәсмиләштерү, әгәр актны рәсмиләштерүнең башка тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнмәгән булса, мондый чараны үткәрү көнендә контроль чара үткәрү урынында башкарыла.

Дәүләт, коммерция, хезмәт яки закон тарафыннан саклана торган башка сердән торган мәгълүматны эченә алган контроль чара нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

Прокуратура органнары тарафыннан килештерелгән контроль чара акты прокуратура органнарына Контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестры ярдәмендә җибәрелә.

4.30. Контроль чаралар турында мәгълүмат Контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрында урнаштырыла.

4.31. Контроль үткәрелә торган затны яки аның вәкилен контроль чара нәтиҗәләре белән таныштыру 248-ФЗ номерлы Федераль законның 88 статьясы нигезендә башкарыла.

Документар тикшерү яисә контроль үткәрелә торган зат белән үзара бәйләнешсез контроль чара үткәрелгән очракта, шулай ук тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча акт төзү аны үткәрү урынында 248-ФЗ номерлы Федераль законның 88 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән контроль гамәлләр башкару аркасында мөмкин булмаса, Контроль органы актны контроль үткәрелә торган затка 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

2023 елның 31 декабренә кадәр контроль үткәрелә торган затка вәкаләтле вазыйфаи затлар башкара торган гамәлләр һәм кабул ителә торган карарлар турында хәбәр итү, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясы нигезендә Контроль органы тарафыннан контроль үткәрелә торган затка документлар һәм белешмәләр җибәрү контроль үткәрелә торган затка электрон формада яки контроль үткәрелә торган зат соратуы буенча хәбәр итү мөмкинлеге булмаган очракта, почта элемтәсен кулланып, шул исәптән кәгазьдә дә гамәлгә ашырылырга мөмкин, дип билгеләргә. Контроль органы, мондый таләп кергән көннән алып ун эш көненнән дә соңармыйча, контроль

үткәрелә торган затка күрсәтелгән документларны һәм (яки) белешмәләрне җибәрә.

2023 елның 31 декабренә кадәр әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән документлар һәм белешмәләр, әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, кәгазьдә (шул исәптән актлар, күрсәтмәләр) төзелергә һәм имзаланырга мөмкин, дип билгеләргә. 2023 елның 31 декабренә кадәр контроль үткәрелә торган затлар белән башка документлар һәм белешмәләр алмашу кәгазьдә башкарыла ала.

Актта бәян ителгән фактлар һәм нәтиҗәләр белән килешмәгән очракта, контроль үткәрелә торган зат 248-ФЗ номерлы Федераль законның 39-43 статьяларында һәм Нигезләмәнең V бүлегендә каралган тәртиптә шикаять җибәрергә хокуклы.

4.32. Контроль чара үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланмаган очракта, бу хакта белешмәләр Контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрына кертелә.

Вәкаләтле вазыйфаи зат мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча киңәшләр бирергә, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычын профилактикалауга юнәлдерелгән башка чаралар үткәрергә хокуклы.

4.33. Контроль чара үткәргәндә контроль үткәрелә торган зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, Контроль органы Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясында каралган вазыйфаларны башкара.

Мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә контроль үткәрелә торган зат тарафыннан тиешенчә үтәлгән икән, Контроль органы тарафыннан 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 3 пунктында каралган чара (административ хокук бозулар өлешендә) кулланылмый, дип билгеләргә.

4.34. Контроль органы Контроль органының күрсәтмәләренең, башка карарларының үтәлешен контрольдә тотучы орган булып тора.

Контроль органы, вәкаләтле вазыйфаи затлар 248-ФЗ номерлы Федераль законның 17 бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

4.35. Контроль органы, вәкаләтле вазыйфаи затлар законнарда билгеләнгән тәртиптә федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, хокук саклау органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Россия Федерациясенең башка субъектларының башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм гражданнар белән хезмәттәшлек итәләр.

## V. Контроль органы карарларына, вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү

5.1. Контроль органының карарларына, вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9

бүлегендә һәм әлеге разделда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

5.2. Контроль органының карарларына, вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка шикаять бары тик судка кадәр шикаять белдерелгәннән соң гына бирелергә мөмкин, эшмәкәрлек белән шөгыльләнми торган гражданнар тарафыннан карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата судка шикаять бирү очракларыннан тыш.

5.3. Хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре, алар фикеренчә, муниципаль җир контроле кысаларында турыдан-туры бозылган контроль үткәрелә торган затлар түбәндәгеләргә карата судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

а) контроль чаралар үткәрү турында карарлар;

б) контроль чаралар актлары;

в) контроль чаралар кысаларында вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләре (гамәл кылмавы).

5.4. Вәкаләтле вазыйфаи затларның (Контроль органы җитәкчесе (җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы заттан тыш)) гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять Контроль органы җитәкчесе (җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы) тарафыннан карала.

Контроль органының карарына, Контроль органы җитәкчесенең (җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы затның) гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять Башкарма комитет җитәкчесе (җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы) тарафыннан карала.

5.5. Шикаять контроль үткәрелә торган зат тарафыннан Нигезләмәнең 5.4 пункты нигезендә билгеләнә торган шикаятьне карап тикшерүгә вәкаләтле органга, Нигезләмәнең 5.6 пунктында каралган очрактан тыш, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталын кулланып, электрон рәвештә тапшырыла. Гражданин тарафыннан шикаять биргәндә, ул гади электрон имза яисә квалификацияле электрон имза белән имзаланган булырга тиеш. Оешма тарафыннан шикаять биргәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Шикаять формасына һәм эчтәлегенә карата башка таләпләр 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнә.

5.6. Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаять, контроль үткәрелә торган зат тарафыннан Нигезләмәнең 5.4 пункты нигезендә билгеләнә торган шикаятьне карап тикшерүгә вәкаләтле органга, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталын кулланмыйча, дәүләт һәм закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, кәгазьдә таршырыла.

5.7. Контроль органы карарына, вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять контроль үткәрелә торган зат үз

хокукларын бозу турында белгән яисә белергә тиеш булган көннән соң утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Нигезле сәбәп аркасында шикаять бирү вакыты чыккан очракта, шикаять биргән зат үтенечнамәсе буенча әлеге срок шикаятьне карау өчен вәкаләтле орган тарафыннан торгызылырга мөмкин.

Шикаятьне биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны кире ала ала. Бу вакытта шикаятьне шул ук нигезләр буенча кабат җибәрү рөхсәт ителми.

Шикаятьтә Контроль органының шикаять белдерелә торган карарын үтәүне туктатып тору турында үтенечнамә булырга мөмкин.

5.8. Шикаятьне карауга вәкаләтле орган шикаятьне теркәгәннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча карар кабул итә:

1) Контроль органының шикаять бирелә торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) Контроль органының шикаять бирелә торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тарту турында;

Шикаять бирелә торган карарның үтәлешен туктатып тору турындагы үтенечнамә буенча карар турында мәгълүмат карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә шикаять биргән затка җибәрелә.

5.9. Шикаять алынган көннән соң биш эш көне эчендә, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 42 статьясында каралган нигезләр (нигез) булганда, шикаятьне карауга вәкаләтле орган тарафыннан шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул ителә.

5.10. Шикаятьне карап тикшерү өчен вәкаләтле орган, шикаятьне караганда, контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирү подсистемасын куллана, шикаятьне карау дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар белән бәйле очраклардан тыш.

5.11. Шикаятьне карап тикшерү өчен вәкаләтле орган, шикаятьне караганда, контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирү подсистемасын куллана, шикаятьне карау дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар белән бәйле очраклардан тыш.

Контроль органы контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә карата судка кадәр шикаять бирү системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләрне тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау, дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирү системасын кулланмыйча гамәлгә ашырыла.

5.12. Шикаять аны теркәгәннән соң егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.

Күрсәтелгән срок, түбәндәге очракларның берсе генә булса да, шикаятьне карап тикшерү өчен вәкаләтле орган тарафыннан егерме эш көненә озайтылырга мөмкин:

- Нигезләмәнең 5.13 пункты нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан өстәмә мәгълүмат һәм документлар соратып алынганда;

- шикаятьне күрсәтелгән вакыт эчендә карап тикшерү объектив характердагы хәлләр аркасында мөмкин булмаса (отпускада булу, вакытлыча эшкә сәләтсезлек, хезмәт командировкасына җибәрү һ. б.);

- шикаятьне карау өчен башка органнар карамагында булган мәгълүматларны алу таләп ителсә.

5.13. Шикаятьне карап тикшерүгә вәкаләтле орган шикаять биргән контроль үткәрелә торган заттан шикаять предметына караган өстәмә мәгълүмат һәм документлар соратып алырга хокуклы.

Контрольүткәрелә торган зат күрсәтелгән мәгълүматны һәм документларны соратып алу җибәргәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау срогы шикаять предметына кирә торган өстәмә мәгълүмат һәм документлар тапшыру турында сорату җибәргәннән моменттан шикаятьне карау өчен вәкаләтле орган тарафыннан аларны алганчыга кадәр, ләкин сорату җибәргән моменттан биш эш көненнән дә артмаган вакытка туктатыла.

Контроль үткәрелә торган заттан шикаять предметына караган өстәмә мәгълүмат һәм документлар алынмау шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый.

Шикаять биргән контроль үткәрелә торган заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынган оешмалар карамагында булган мәгълүматны һәм документларны соратып алу рөхсәт ителми.

Шикаятьне биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнче, үз теләге белән шикаять предметына караган өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы.

5.14. Кабул ителгән карарның һәм (яки) кылынган гамәлнең (гамәл кылмауның) законлылыгын һәм нигезлелеген раслау бурычы Контроль органына йөкләнә.

5.15. Шикаятьне карап тикшерү өчен вәкаләтле орган шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндермичә калдыра;

2) Контроль органы карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгара;

3) Контроль органы карарын тулысынча юкка чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип таный һәм асылдагыча (по существу), шул исәптән кирәк булганда билгеле бер гамәлләр башкару турында карар чыгара.

5.16. Шикаятьне карап тикшерү өчен вәкаләтле органның кабул ителгән карарның нигезләмәсен, аны үтәү вакытын һәм тәртибен үз эченә алган карары дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталында һәм

(яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең төбәк порталындаконтроль үткәрелә торган затның шәхси кабинетында кабул ителгән көннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Контроль органы карары, дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, контроль үткәрелә торган затка кабул иткәннән соң бер эш көне эчендә кәгазьдә җибәрелә.

## VI. Контроль органы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын бәяләү

6.1. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын бәяләү 248-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.2 Муниципаль җир контроленең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан күрсәткечләре, муниципаль җир контроле өчен индикатив күрсәткечләр Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында күрсәтелгән.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә 1 нче кушымта

**Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль җир контролен тормышка ашырганда гражданнар, юридик затлар һәм (яки) шәхси эшмәкәрләр тарафыннан файдаланыла торган алар хокукында булган җир кишәрлекләрен куркынычның билгеле бер категориясенә кертү критерийлары**

1. Урта куркыныч категориясенә керә:

а) җитештерү һәм куллану калдыкларын күмү һәм урнаштыру, зиратларны урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләре;

б) гомуми кулланылыштагы су объектларының яр буе полосасы чикләрендә яки чиге янәшәсендә урнашкан җир кишәрлекләре.

2. Уртача куркыныч категориясенә түбәндәге җир кишәрлекләре керә:

а) торак пунктлар җирләре категориясенә керүче һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясенә керә торган җирләр һәм (яки) җир кишәрлекләре, урман фонды җирләре, махсус саклана торган территорияләр һәм объектлар, запас җирләр белән чиктәш җирләр;

б) сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона, иминлек һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә керә торган җирләр, автомобиль юллары, тимер юллар, торба үткәргеч транспорт, электр линияләре һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясенә керә торган җирләр һәм (яки) җир кишәрлекләре белән чиктәш җирләрдән тыш;

в) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясенә керә һәм торак пункт җирләре категориясенә караган җирләр һәм (яки) җир кишәрлекләре белән чиктәш.

3. Түбән куркыныч категориясенә урта яки уртача куркыныч категориясенә кертелмәгән барлык башка җир кишәрлекләре керә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле өчен мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы (риск) индикаторлары исемлеге**

1. Тикшерү чарасын үткәрү нәтиҗәсендә билгеләнгән юридик зат, шәхси эшмәкәр, җир кишәрлеге гражданины тарафыннан кулланыла торган мәйданның күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларда булган җир кишәрлегенең мәйданына туры килмәве.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр, гражданин тарафыннан җир кишәрлегеннән фактта файдалануның Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында булган, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларда булган җир кишәрлегеннән файдалану максатларына туры килмәве.

3. Җир кишәрлеген бирү вакытыннан алып өч елдан артык вакыт узган яки җир кишәрлеген арендалау килешүендә күрсәтелгән җир кишәрлеген үзләштерү срогы тәмамланган, ә җир кишәрлегендә характерлы үзгәрешләр күзәтелмәү шартларында җир кишәрлеген озак вакыт дәвамында үзләштермәү (капиталь төзелеш объекты булмау, төзелеш эшләре алып бару һәм рөхсәт ителгән куллану һәм бирү шартлары нигезендә җир участогыннан файдалану буенча башка гамәлләр булмау).

4. Җир кишәрлекләрен файдалану өчен нигез булып тора торган документларны рәсмиләштерүгә мәҗбүри таләпләрне үтәмәү.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә 3 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроленең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан күрсәткечләре, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле өчен индикатив күрсәткечләр

| **Төп күрсәткечләр** | **Максатчан кыйммәтләр** |
|---|---|
| Ачыкланган җир законнарын бозу очраклары санынннан бетерелгән хокук бозулар проценты | 70% |
| Чираттагы календарь елына планлы контроль чаралар үткәрү планын үтәү проценты | 100% |
| Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба – Контроль органы) һәм (яки) аның вазыйфаи затларының контроль чаралар үткәргәндә гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата нигезләнгән шикаятьләр проценты | 0% |
| Тикшерү чараларының гамәлдән чыгарылган нәтиҗәләре проценты | 0% |
| Тиешле административ йогынты чаралары күрелмәгән нәтиҗәле контроль чаралар проценты | 5% |

| **1.** | **Үткәрелгән чаралар параметрларын характерлаучы индикатив күрсәткечләр** | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.1. | План (рейд) биремнәренең (караулар) үтәлеше | Врз = (РЗф / РЗп) х 100 | Врз – план (рейд) биремнәренең (караулар) үтәлеше, %<br>РЗф – уздырылган план (рейд) биремнәре (караулар) саны (берәмлек)<br>РЗп – расланган план (рейд) биремнәре (караулар) саны (берәмлек) | 100% | Расланган план (рейд) биремнәре (караулар) |
| 1.2. | Планнан тыш тикшерүләрнең үтәлеше | Ввн = (Рф / Рп) х 100 | Ввн – планнан тыш тикшерүләрнең үтәлеше<br>Рф – уздырылган планнан тыш тикшерүләрнең саны (берәмлек)<br>Рп – планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен | 100% | Контроль органына кергән хатлар һәм шикаятьләр |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | күрсәтмәләр саны (бер.) | | |
| 1.3. | Нәтиҗәләр буенча шикаять бирелгән тикшерүләр өлеше | Ж x 100 / Пф | Ж – шикаятьләр саны (берәмлек)<br>Пф – уздырылган тикшерүләр саны | 0% | |
| 1.4. | Нәтиҗәләре дөрес түгел дип табылган тикшерүләр өлеше | Пн x 100 / Пф | Пн – гамәлдә түгел дип табылган тикшерүләр саны (берәмлек)<br>Пф – уздырылган тикшерүләр саны (берәмлек) | 0% | |
| 1.5. | Милекче булмау сәбәпле үткәреләалмаган планнан тыш тикшерүләр өлеше һ. б. | По x 100 / Пф | По – тикшерелүче зат булмау сәбәпле үткәрелмәгән тикшерүләр (берәмлек)<br>Пф – уздырылган тикшерүләр саны (берәмлек) | 30% | |
| 1.6. | Планнан тыш тикшерүләр үткәрү турында прокуратурага килештерүгә җибәрелгән, аларны килештерүдән баш тартылган гаризаларның өлеше | Кзо x 100 / Кпз | Кзо – гаризалар буенча килешүдән баш тарту килгән гаризалар саны (берәмлек)<br>Кпз – килештерүгә бирелгән гаризалар саны | 10% | |
| 1.7. | Нәтиҗәләре буенча материаллар карарлар кабул итү өчен вәкаләтле органнарга җибәрелгән тикшерүләр өлеше | Кнм x 100 / Квн | К нм – вәкаләтле органнарга җибәрелгән материаллар саны (берәмлек)<br>Квн – ачыкланган хокук бозулар саны (берәмлек) | 100% | |
| 1.8. | Үткәрелгән профилактик чаралар саны | | | Шт. | |
| **2.** | Файдаланылган хезмәт ресурслары күләмен характерлаучы индикатив күрсәткечләр | | | | |
| 2.1. | Штат берәмлекләре саны | | | Кеше | |
| 2.2. | Муниципаль контроль органы хезмәткәрләренә контроль чаралар | Км / Кр= Нк | Км – контроль чаралар саны (берәмлек)<br>Кр – муниципаль контроль органы | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | йөкләмәсе | | хезмәткәрләре саны (берәмлек)<br>Нк – 1 хезмәткәргә йөкләмә (берәмлек) | | |